РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
САРМАНОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
«ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ул. Молодежная, д. 1 а,
с. Лешев Тамак, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр урамы, 1 а йорт,
Ләшәү Тамак авылы, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru

ОГРН 1021601312182 ИНН/КПП 1636001322/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2017елның 19 сентябре № 24

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Ләшәү-Тамак авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Ләшәү-Тамак авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ.:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
"2018 елда Ләшәү-Тамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

1).Җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп), шул исәптән:
- Ләшәү Тамак, Сарайлы, Дүсем, Түбән Ләшәү торак пунктларында яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру.
- махсуслаштырылган техника өчен печән чапкычлар сатып алу,
- махсуслаштырылган техниканы карап тоту.

2). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә, шул исәптән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру:
- Ләшәү Тамак, Сарайлы, Дүсем, Түбән Ләшәү авылларында кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.
- Ләшәү Тамак авылында юлларны ремонтлау .

3). Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:
- Җыну көне, Сабантуй, өлкәннәр көне бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр алу.
4). Җирләү урыннарын карап тоту һәм күмү хезмәтләре күрсәтүне оештыру, шул исәптән:
- Ләшәү Тамак авылы зираты коймасын әйләндереп алу.
- Сарайлы авылы зиярәтына чүкеч алу.

ЮК ӘЛЕ".

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ләшәү-Тамак Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы И. З. Хабибуллин